ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

10.02.2021 Казан шәһәре № 12-1/тэ-2021

Казан шәһәре, Дорожная урамы, 26 һәм Набережная урамы, 2В адресы буенча урнашкан котельныйлардан куллану-чыларга «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан житкерелә торган жылылык энергиясе (егәрлеге) өчен тарифлар билгеләү хакында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Казан шәһәре, Дорожная урамы, 26 һәм Набережная урамы, 2В адресы буенча урнашкан котельныйлардан кулланучыларга «Казэнерго» акционерлык җәмгыяте тарафыннан житкерелә торган жылылык энергиясе (егәрлеге) өчен әлеге карар кушымтасына туры китереп, календарь буенча бүленгән тарифлар билгеләргә.
2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2021 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач гамәлгә керә.

Рәис А.С.Груничев

Татарстан Республикасы
Тарифлар буенча дәүләт комитетының
10.02.2021 № 12-1/тэ-2021
карарына кушымта

# Казан шәһәре, Дорожная урамы, 26 һәм Набережная урамы, 2В адресы буенча урнашкан котельныйлардан кулланучыларга «Казэнерго» АҖ тарафыннан җиткерелә торган җылылык энергиясе (егәрлеге) өчен календарь буенча бүленгән тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | су | Басым астында сайланган пар | | | | Әче һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 кг/см$^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 кг/см$^2$ кадәр | 7,0-13,0 кг/см$^2$ кадәр | артык 13,0 кг/см$^2$ | |
| | Казан шәһәре | | | | | | | |
| 1 | Казан шәһәре, Дорожная урамы, 26 һәм Набережная урамы, 2В адресы буенча урнашкан котельныйлардан кулланучыларга «Казэнерго» АҖ | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 10.02.2021 № 12-1/тэ-2021 карар үз көченә кергән көннән башлап 30.06.2021 кадәр | 1480,67 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1602,30 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән)* | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 10.02.2021 № 12-1/тэ-2021 карар үз көченә кергән көннән башлап 30.06.2021 кадәр | 1776,80 | - | - | - | - | - |
| | | 01.07.2021 башлап 31.12.2021 кадәр | 1922,76 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының тариф
чишелешләрен кабул итүне оештыру,
контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге